КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 декабрь г.Казань № 1102

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1170 нче, 2020 ел, 28 гыйнвар, 45 нче, 2022 ел, 23 декабрь, 1400 нче, 2024 ел, 13 гыйнвар, 8 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ведомствоара эшче төркем составыннан А.К.Кирпичниковны, А.М.Фроловны чыгарырга;

ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Прокаева Алия Наил кызын | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Торак-коммуналь хуҗалык идарәсенең торак фонды объектларын эксплуатацияләү һәм территорияләрне төзекләндерү бүлеге башлыгын |

| | |
|---|---|
| Урманов Даян Ренат улын | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесен |
| Шәйдуллин Дамир Фәрит улын | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын; |

Тыгин Александр Васильевич вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин